СОВЕТ
НОВОКЫРЛАЙСКОГО
СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
АРСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
ул.Центральная, д. 3, с.Новый Кырлай,
Арский муниципальный район, 422035

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
АРЧА МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
ЯҢА КЫРЛАЙ
АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ
СОВЕТЫ
Үзәк урам, 3 йорт, Яңа Кырлай авылы,
Арча муниципаль районы, 422035

Тел. (84366)56-7-32, факс (84366)56-7-34, E-mail: Nkrl.Ars@tatar.ru

**Арча муниципаль районы**
**Яңа Кырлай авыл җирлеге Советы**
**КАРАРЫ**

« 16 » июль 2021ел № 27

**Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы Яңа Кырлай авыл җирлеге Советының 2021 елның 17 февралендәге 15 номерлы“Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы Яңа Кырлай авыл җирлеге территориясендәРоссия Федерациясе дәүләт урман фонды җиренә һәм физик һәм юридик затларның хосусый милкендә булган җирләргә кермәгән яшел үсентеләрне кисү тәртибе турындагы Нигезләмәне раслау хакында” карарына үзгәрешләр кертү турында**

Россия Федерациясе Урман кодексы, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Россия Федерациясе Федераль законы, «Әйләнә-тирә мохитне саклау турында» 2002 елның 10 гыйнварындагы 7-ФЗ номерлы Федераль закон, Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы Яңа Кырлай авыл җирлеге Уставы нигезендә, Яңа Кырлай авыл җирлеге территориясендә Россия Федерациясе дәүләт урман фонды җирләренә һәм физик һәм юридик затлар милкендә булган җирләргә кермәгән яшел үсентеләрне рациональ файдалану, саклау һәм яңадан торгызу максатыннан Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы Яңа Кырлай авыл җирлеге Советы карар бирде:

1. Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы Яңа Кырлай авыл җирлеге Советының 2021 елның 17 февралендәге 15 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы Яңа Кырлай авыл җирлеге территориясендә Россия Федерациясе дәүләт урман фонды җирләренә һәм физик һәм юридик затларның хосусый милкендә булган җирләргә кермәгән яшел үсентеләрне кисү тәртибе турында Нигезләмәгә түбәндәге үзгәрешләр кертергә:

1) 3.5 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«3.5. Авыл җирлеге башкарма комитеты гариза бирүче хат-гаризасы, яшел үсентеләрне техник тикшерү акты, киселгән агач өчен түләүне (бәя) исәпләү нигезендә авыл җирлеге башкарма комитеты җитәкчесенең авыл җирлеге территориясендә яшел үсентеләрне кисүгә гариза бирү көнен дә кертеп, 13 көн эчендә рөхсәт итү турындагы күрсәтмәсе проектын әзерли.»;

2) 3.11 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«3.11. Агач кискән өчен түләүне башкармыйча, агач һәм куакларны кисү түбәндәге очракларда авыл җирлеге башкарма комитеты тарафыннан рөхсәт ителә ала:

3.11.1. яшел үсентеләрне тәрбияви кисүләр, санитар кисүләр һәм реконструкцияләү;
3.11.2. авария һәм башка гадәттән тыш хәлләрне бетерү, шул исәптән җир асты коммуникацияләрен һәм капиталь инженерлык корылмаларын ремонтлау вакытында;
3.11.3. әгәр дәүләт санэпидемнадзор бәяләмәсе булса,торак һәм җәмәгать биналарында яктылык режимын боза торган агач һәм куакларны кисү;
3.11.4. җимерелү куркынычы тудыра торган авария хәлендәге (корыган) агачлар һәм куакларны кисү ».

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы рәсми хокукый мәгълүмат порталында бастырып чыгарырга һәм Арча муниципаль районының рәсми сайтында "Җирлекләр" бүлегендә урнаштыру юлы белән халыкка җиткерергә.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемә алам.

Яңа Кырлай авыл
җирлеге башлыгы Г.Г.Сәфәров

СОВЕТ НОВОКЫРЛАЙСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
ИНН1609012702